Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Аккүл авылында
гражданнар җыены
КАРАРЫ

2023 елның 19 ноябре №2

2024 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлегенең Аккүл авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге Аккүл авылы гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге Аккүл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, күп балалы гаиләләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

I. торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
Аккүл авылында Колхоз урамы, Комсомол урамы буенча вак таш юлларны чокырлы ремонтлау;
Аккүл авылына юлларны кардан чистарту (Күпер урамы, Колхоз урамы, Комсомол урамы).

II. Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:
- Аккүл авылының каптированный чишмәсен ремонтлау;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Ивановка авылы, Яшьлек урамы, 5, Аккүл авылы, Колхоз урамы, 16Б, Медведка авылы, Дорожная урамы, 32, Михайловка авылы, Центральная урамы, 4 йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
Ивановка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы А.П.Бодряева